# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМБАКТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

№68-3 14.09.2022

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 августындагы 38-4 номерлы карары белән расланган Ямбакты авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга еллык түләүле ял бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

РФ Хезмәт Кодексы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, ТР Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 августындагы 38-4 номерлы карары белән расланган Ямбакты авыл җирлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга еллык түләүле ял бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«6. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә ел саен өстәмә түләүле отпуск озынлыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпуск һәм ел саен өстәмә түләүле отпускның гомуми озынлыгы 40 календарь көннән артып китә алмый. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен өч календарь көн дәвамында ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә».

1.2. Нигезләмәнең 7 пунктын "Хезмәт Кодексы башкача каралмаган булса" сүзләренә өстәргә;

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Ямбакты авыл җирлеге башлыгы И. Ә. Галәветдинов

СОВЕТ ЯМБУХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯМБУХТИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА